ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.04.2024 п.г.т.Алексеевское № 119

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 18.03.2022 ел, № 86 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына аукционнар үткәрү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 18.03.2022 ел, № 86 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына аукционнар үткәрү тәртибе турында» карарына 1 нче кушымта «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион үткәрү комиссиясе турында Нигезләмә» яңа редакциядә бәян итәргә (Кушымта №1).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 18.03.2022 ел, № 86 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына аукционнар үткәрү тәртибе турында» карарына 2 нче кушымта «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион үткәрү комиссиясе составы» яңа редакциядә бәян итәргә (Кушымта №2).
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
01.04.2024 ел, № 119
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион үткәрү буенча комиссия турында нигезләмә**

1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына электрон аукцион үткәргәндә аукцион комиссиясе эшчәнлеге тәртибен билгели (алга таба – аукцион).

2. Аукцион комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 18.03.2022 ел, № 86 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына аукционнар үткәрү тәртибе турында» карары белән җитәкчелек итә.

3. Аукцион комиссиясе аукцион үткәрү процессында аукционда катнашуга гаризаларны объектив карауны һәм аукцион үткәрү юлы белән ачыклык, үтә күренмәлелек, конкурентлык принципларын үтәүне тәэмин итә.

2 нче бүлек. Аукцион комиссиясен формалаштыру тәртибе

4. Аукцион комиссиясе коллегиаль орган булып тора.

5. Аукцион комиссиясенең шәхси составы Башкарма комитет карары белән раслана.

6. Аукцион комиссиясе аукцион комиссиясе рәисеннән, аукцион комиссиясе рәисе урынбасарыннан, аукцион комиссиясе секретаре, аукционист һәм аукцион комиссиясе әгъзаларыннан тора. Аукцион комиссиясе рәисе урынбасары, аукцион комиссиясе секретаре һәм (яки) аукционист булмаган очракта, тиешле функцияләрне үтәү аукцион комиссиясе рәисе тарафыннан аукцион комиссиясенең башка әгъзаларына йөкләнергә мөмкин.

7. Аукцион комиссиясе әгъзалары булып аукцион нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган физик затлар (шул исәптән аукционда катнашу өчен гариза биргән физик затлар, яисә күрсәтелгән гаризаларны биргән оешмалар штатында торучылар) яисә аукционда катнашучылар йогынты ясый алган физик затлар (шул исәптән әлеге оешмаларда катнашучы (акционер) булган физик затлар, аларның идарә органнары әгъзалары була алмый, аукционда катнашучыларның кредиторлары).

8. Аукцион комиссиясе составында әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән затлар ачыкланган очракта, аукцион комиссиясен булдыру турында карар кабул иткән орган аларны аукцион нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынмаган һәм катнашучылар йогынты ясый алмаган башка физик затлар белән кичекмәстән алыштырырга тиеш.

9. Аукцион комиссиясе әгъзасын алмаштыру аукцион комиссиясен булдыру турында карар кабул иткән аукцион Заказчысы карары буенча гына рөхсәт ителә.

## 3 нче бүлек. Аукцион комиссиясе функцияләре

10. Аукцион комиссиясенең төп функцияләре булып:

1) аукционда катнашуга гаризаларны карау һәм дәгъвачыларны аукционда катнашуга кертү яки дәгъвачыларны аукционда катнашудан баш тарту турында карар кабул итү;

2) аукционга тапшырылган мәгълүматларның һәм документларның дөреслеген тикшерү;

3) дәгъвачыны аукционда катнашудан читләштерү турында карар кабул итү;

4) аукцион үткәрүне оештыру;

5) аукцион җиңүчесен билгеләү;

6) реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү турында килешү төзүдән качкан аукцион җиңүчесен тану турында карар кабул итү;

7) катнашучыларны аукционга кертү турында беркетмәләр, аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәләр һәм башка беркетмәләр алып бару.

## 4 нче бүлек. Аукцион комиссиясенең хокуклары һәм бурычлары

11. Аукцион комиссиясе әгъзалары хокуклы:

1) аукционда катнашу өчен гариза төзүче барлык документлар һәм мәгълүматлар белән танышу;

2) аукцион комиссиясе утырышларында көн тәртибе мәсьәләләре буенча чыгыш ясау;

3) гаризаларны карау беркетмәсенә, аукцион беркетмәсенә, Россия Федерациясе законнарына һәм башка норматив-хокукый актларга туры килүенә кул куярга һәм тикшерергә;

4) аукцион комиссиясе караган мәсьәлә буенча үзенең аерым фикерен язмача бәян итәргә, ул тиешле беркетмәгә кушыла.

12. Аукцион комиссиясе әгъзалары бурычлы:

1) аукцион комиссиясе утырышларында, җитди сәбәпләр (вакытлыча эшкә яраксызлык, командировка һәм башка җитди сәбәпләр)аркасында килеп чыккан очраклардан тыш, катнашырга;

2) үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итү;

3) аукционда катнашуга гаризаларны карау барышында аларга билгеле булган дәүләт, хезмәт яки коммерция серен тәшкил иткән мәгълүматны ачуга юл куймаска.

13. Аукцион комиссиясе рәисе (комиссия әгъзасы, аның урынбасары):

1) аукцион комиссиясе эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

2) утырышны хокуклы дип игълан итә яки кворум булмау сәбәпле аны күчерү турында карар чыгара,

3) аукцион комиссиясе утырышларын ача һәм алып бара, тәнәфесләр игълан итә;

4) тикшерелә торган мәсьәләләрне карау тәртибен билгели;

5) Комиссия эшенә экспертларны, эксперт оешмасын җәлеп итү мәсьәләсен аукцион комиссиясе фикер алышуына чыгара.

14. Аукцион комиссиясе секретаре, утырыш уздырылганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча, аукцион комиссиясе әгъзаларына утырышның урыны, датасы һәм вакыты турында хәбәр итә, аукцион комиссиясе утырышларын әзерли, шул исәптән кирәкле документларны рәсмиләштерә һәм тарата, аукцион комиссиясе әгъзаларына аларның функцияләренә кагылышлы барлык мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирә, утырышлар барышында катнашучыларны аукционга кертү турында беркетмә алып бара, аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә , шулай ук аукцион комиссиясе эшчәнлеге белән бәйле оештыру-техник характердагы башка гамәлләрне гамәлгә ашыра.

5 нче бүлек. Аукцион комиссиясенең эш тәртибе

15. Аукцион комиссиясе, әгәр аукцион комиссиясе утырышында аның сан составының өчтән ике өлеше булса, әлеге Тәртиптә каралган функцияләрне башкарырга хокуклы.

16. Рәис (комиссия әгъзасы, аның урынбасары) аукцион комиссиясе утырышын ачу һәм ябу турында игълан итә.

17. Аукцион комиссиясе карары аның утырышында катнашучы аукцион комиссиясе әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, аукцион комиссиясе утырышында рәислек итүче тавыш биргән карар кабул ителгән дип санала.

18. Аукцион комиссиясе аукционда катнашу өчен гариза составында документлар һәм мәгълүматлар булу-булмавын аукцион документациясе, Россия Федерациясе законнары белән аукционда катнашу өчен гаризага куелган таләпләргә ярашлы рәвештә тикшерә.

19. Аукцион комиссиясе аукцион документациясендә билгеләнгән срокларда аукционда катнашуга гаризаларны карый.

20. Аукцион комиссиясе аукционда катнашуга гаризаларны карау нәтиҗәләре нигезендә катнашучыны аукционда катнашуга рөхсәт итү һәм аукционда катнашуга гариза биргән катнашучыны аукционда катнашучы дип тану яки мондый катнашучыны аукционда катнашудан баш тарту турында карар кабул итә һәм катнашучыларны аукционга кертү турында беркетмә рәсмиләштерелә.

21. Катнашучыларны аукционга кертү турындагы беркетмәгә аукцион комиссиясенең барлык әгъзалары аукционда катнашуга гаризаларны карау тәмамланган көнне кул куя.

22.Аукцион нәтиҗәләре аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә теркәлә, ул аукцион комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Аукцион комиссиясе әгъзалары, аукцион комиссиясе кабул иткән карар белән килешмичә, беркетмә текстында тиешле сылтама белән беркетмәгә кушымта рәвешендә үз фикерләрен язмача әйтергә хокуклы.

23.Аукцион комиссиясе эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү, шул исәптән аукцион комиссиясе утырышларын үткәрү максатларында уңайлы бина, оргтехника һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин итү аукцион Заказчысы тарафыннан башкарыла.

24. Аукцион комиссиясе әгъзалары йөкләнгән бурычларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

**Башкарма комитетның**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
01.04.2024 ел, № 119
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион үткәрү комиссиясе составы**

Р. С. Язынин-комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Н. А. Фомина - комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;

Әгъзалар:

О. Н. Леденцов – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы;

Э. Н. Павлова – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

Г. Ә. Йосыпова – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе;

Комиссия секретаре (тавыш бирү хокукы юк):

И.В. Алексеева – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль сатып алулар секторы мөдире.

**Башкарма комитетның**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**